КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзм авыл җирлеге составына керүче Олыяз торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

07.09.2022 № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына таянып, 2022 елның 07 сентябрендә узган гражданнар җыенында «2023 нче елда Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенә керүче Олыяз торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең Эзмә торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800,0 (сигез йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- ТР Саба муниципаль районы Олыяз торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (Грунтны эшләү, ком нигезен урнаштыру, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, сууткәргеч торбаларны җиһазлау, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Олыяз торак пункты территориясен төзекләндерү;
- Олыяз авылының зиратын һәм аның тирәләрен карап тоту.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 227 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 136 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 136 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге составына керүче Олыяз торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.
2. “2023 нче елда Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенә керүче Олыяз торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең Олыяз торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800,0 (сигез йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?” дигән мәсьәлә

буенча һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) ТР Саба муниципаль районы Олыяз торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (Грунтны эшләү, ком нигезен урнаштыру, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, сууткәргеч торбаларны җиһазлау, килешү буенча эшләр өчен түләү)

2) Олыяз торак пункты территориясен төзекләндерү;

3) Олыяз авылының зиратын һәм аның тирәләрен карап тоту, карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/izma адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Эзмә авыл
җирлеге башлыгы урынбасары Р.Г.Әхмәтов